# КАРАР

2022 елның 23 ноябре № 1

**Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Югары Шөн авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәсе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 23 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлегенең Югары Шөн авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәкләрдән; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Югары Шөн авылында Чапаев, Октябрь, Май, урамнарында вак таш җәеп, юллар төзү һәм ремонтлау; проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Югары Шөн авылында Октябрь урамыннан Май урамына чыгу юлын ремонтлау, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Югары Шөн авылында юлларны җәен һәм кышын карап тоту һәм чистарту;
- Югары Шөн авылында урам яктырткычларын ремонтлау һәм сатып алу;
- Югары Шөн авылында спорт мәйданчыгын төзекләндерү, спорт һәм балалар җиһазлары һәм инвентарьлары сатып алу һәм урнаштыру: проект - смета документлары;
- Югары Шөн авылына янгын гидрантлары, янгын краннары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары;
- Югары Шөн авылында зират коймасын ремонтлау һәм зиратны карап тоту, ритуаль хезмәтләр күрсәтү өчен инвентарь алу, проект-смета документлары;
- Югары Шөн авылында су башнясын һәм суүткәргеч челтәрне карап тоту һәм ремонтлау , проект-смета документлары;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 195 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 103.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 103 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге Югары Шөн авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлегенең Югары Шөн авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәкләрдән; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Югары Шөн авылында Чапаев, Октябрь, Май, урамнарында вак таш җәеп, юллар төзү һәм ремонтлау; проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Югары Шөн авылында Октябрь урамыннан Май урамына чыгу юлын ремонтлау, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Югары Шөн авылында юлларны җәен һәм кышын карап тоту һәм чистарту;
- Югары Шөн авылында урам яктырткычларын ремонтлау һәм сатып алу;
- Югары Шөн авылында спорт мәйданчыгын төзекләндерү, спорт һәм балалар җиһазлары һәм инвентарьлары сатып алу һәм урнаштыру: проект - смета документлары;
- Югары Шөн авылына янгын гидрантлары, янгын краннары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары;
- Югары Шөн авылында зират коймасын ремонтлау һәм зиратны карап тоту, ритуаль хезмәтләр күрсәтү өчен инвентарь алу, проект-смета документлары;
- Югары Шөн авылында су башнясын һәм суүткәргеч челтәрне карап тоту һәм ремонтлау , проект-смета документлары;

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Рәислек итүче, Важашур авыл җирлеге башлыгы П.Л. Иванов